РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ИСКЕ КАЗИЛЕ**
**авыл җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Центральная, 7,д. Караталга, 422834
тел. (8-834-77)30-4-39, факс: (8-834-77) 30-4-39
ОКПО 93064642 , ОГРН 1061672003425
ИНН/КПП 1622004595/162201001

Үзәк урамы, 7, Каратал авылы, 422834,
тел(8-834-77)30-4-39. , факс: (8-834-77)30-4-39
ОКПО 93064642, ОГРН 1061672003425
ИНН/КПП 1622004595/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**“13” апрель 2019 ел** **№ 39**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган документлар күчермәләрен һәм алардан өземтәләрне таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең 2018 елның 15 декабрендә кабул ителгән 12 номерлы «Документлар күчермәсенә тугрылык һәм алардан өземтә алу буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон," Җирлекләрнең җирле администрацияләре башлыклары һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында инструкцияне раслау хакында” Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 06.06.2017 ел, № 97 “Муниципаль районнарның җирле администрацияләре башлыклары һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарының махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан» боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Башкарма комитетының 15.12.2018 ел, № 12 карары белән расланган “Документлар күчермәләренә тугрылык һәм алардан өземтәл алу буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карарына (алга таба – регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

регламентның 2.5 бүлегендәге 2 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Аларның күләме бер биттән артып киткән күчермә яки өземтәләргә тугрылык таныклау өчен тәкъдим ителгән документлар аларны беркетү юлы

белән яки аларның бөтенлегенә шик тудырмый торган башка ысул белән тәэмин ителергә тиеш.»;

регламентның 2 бүлегендәге 2.9 пунктының икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигез каралмаган.

Баш тарту өчен нигез:

1) мондый гамәлләр Россия Федерациясе законнарына каршы килә;

2) гамәл башка җирлек яки муниципаль районның җирле үзидарә органының вазыйфаи заты тарафыннан (мирас мөлкәтен саклауга карата чаралар кабул итүгә карата һәм кирәк булган очракта аларга идарә итү буенча чаралар күрүгә карата кулланыла) яисә нотариус тарафыннан башкарылырга тиеш;

3) нотариаль гамәлләр башкару турында үтенеч белән эшкә яраксыз граждан яки кирәкле вәкаләтләргә ия булмаган вәкил, яшәү урыны буенча теркәлмәгән яисә җирлектә булу мөмкинлеге булмаган граждан мөрәҗәгать итте;

4) мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә түгел, йә тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар.»;

регламентның 2 бүлегендәге 2.10 пунктының икенче абзацындагы җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Физик һәм юридик затлар өчен дәүләт пошлинасын түләү буенча ташламалар Россия Федерациясе Салым Кодексының 333.35 статьясындагы 1 пунктының 11, 12 пунктчалары, 333.38 статьясы белән билгеләнгән.».

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Иске Казиле Авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Х.Сагьдиев**